Марсель Галиевнең иҗади мирасын өйрәнү, пропогандалау максатыннан

мәктәп укучылары һәм укытучылар арасында

I Республикакүләм Марсель Галиев укулары

НИГЕЗЛӘМӘСЕ

Марсель Галиев укулары күренекле якташ язучының иҗатын өйрәнү, пропагандалау, "2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы"н тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

1. Укуларның максаты:

Укучыларны һәм укытучыларны фәнни-эзләнү эшләренә тарту;
Матур әдәбият аша туган телгә, милләткә карата хөрмәт тәрбияләү;
Гомуми урта белем бирү йортларында белем бирүче укытучыларны үстерү юлларын билгеләү, тәҗрибә уртаклашуга тарту.

2. Катнашучылар:

I Республикакүләм Марсель Галиев укуларында гомуми белем бирү учреждениеләренең 8-11 нче сыйныф укучылары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнаша.

3. Бәйгене оештыручылар:

Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге, Татарстан Республикасы язучылар Союзы, Азнакай муниципаль районының мәгариф бүлеге.

4. Үткәрү шартлары һәм тәртибе:

Конкурс **2 турда** үткәрелә:

1 тур – 2014 елның 5 апреленә кадәр оештыру комитеты бәйгедә катнашу өчен гаризалар, фәнни эшләр, тезислар кабул итә. Гариза, тезис һәм фәнни эшне **ilgiza.ilyasova@edu.tatar.ru** адресына җибәрергә кирәк (Хәбәрләшү өчен тел.: 8(85592) 7-66-79, 89872137116 - Илгизә Миркасыймовна; 8(8342)33-75-98, 89093088105 – Сиринә Миннегалимовна)

2014 елның 5-17 апреледә эшләр жюри тарафыннан тикшерелеп, иң яхшы эшләргә 2 нче турга чакыру җибәрелә. Эшләр жюри тарафыннан тикшерелә һәм бәяләнә, таләпләр туры килгән эшләрнең авторларына конференциядә катнашу өчен чакыру "Азнакай шәһәре гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе сайтына куела.

2 тур - 2014 елның 24 апреледә укулар Татарстан Республикасы "Азнакай шәһәре гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә үткәрелә.

Укытучы яки укучы үзе сайлаган темага чыгыш әзерли (эзләнү эше, мастер-класс, проект эше, конкрет методика белән эшкәртелгән практик яки эксперименталь материал булырга мөмкин). Эзләнү эшләренә түбәндәге юнәлешләр тәкъдим ителә:

1. М. Галиев – танылган әдип – шагыйрь, прозаик, публицист һәм драматург.
2. М. Галиев иҗатын мин ничек күзаллыйм.
3. М. Галиев иҗатында юмор һәм сатира. («Шаян истәлекләр», «Туган як мәзәкләре» — III томда; «Йотымлап-йотымлап елмаю» — VI томда).
4. М. Галиевнең драматургия, әдәби тәрҗемә һәм җыр текстлары иҗат итү өлкәләрендәге үзенчәлекле уңышлары.
5. М. Галиев иҗатында туган як темасы. (Шигырьләр — I, II том; проза — III– IV том).
6. М.Галиев иҗатында фәлсәфи уйланулар ("Догалы еллар" (V том); "Рух" әсәре (II том) буенча).

5. Оештыру взносы – 300 сум

6. Эшләрне бәяләүгә таләпләр:

Эшләр татар телендә, басма өчен текстның күләме 3 басма биттән артмаска тиеш. Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр булырга мөмкин). Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman - 14. интервал -1,5; уннан - 1,5; сулдан 2,5, астан - 2; өстән - 1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла. Презентация өчен таләпләр: Microsoft Power Point 2003 форматында саклана.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме (устав буенча), район, укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, тема язылы.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.
Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.